МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.11.2016 Казан шәһәре № 359

Норматив хокукый актларга һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен раслау турында

«Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары һәм «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә борам:

1. Аерым норматив хокукый актларга һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан әзерләнә торган норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр А.А. Здунов

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2016 елның 17 ноябрендәге 359 номерлы боерыгы белән расланган

**Норматив хокукый актларга һәм һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе**

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының (алга таба – Министрлык) норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру, шулай ук Министрлык тарафыннан эшләнә торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алу кагыйдәләрен билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Министрлыкның норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлары проектларына, шулай ук Министрлык тарафыннан әзерләнә торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларына (алга таба – актлар һәм актлар проектларына) карата үткәрелә.

1.3. Коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып актларда һәм актлар проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба бетерү тора.

II. Актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү

2.1. Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – Министр) Министрлыкта актларга һәм актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затны (алга таба – вазыйфаи зат) билгеләп куя. Күрсәтелгән вазыйфаи зат шулай ук Министрлыкта коррупциягә каршы экспертизага кергән Министрлыкның норматив хокукый актларын һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналын алып бару өчен җаваплы булып тора, анда коррупциягә каршы экспертизага кергән актлар һәм актлар проектлары, экспертиза үткәрү вакыты һәм нәтиҗәләре турында белешмәләр чагылдырыла. Журнал әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча алып барыла.

2.2. Актлар һәм актлар проектлары, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен, аның инициативасы буенча әлеге акт кабул ителгән структур бүлекчә җитәкчесе (акт проектын эшләү өчен җаваплы) тарафыннан вазыйфаи затка җибәрелә.

2.3. Актлар һәм актлар проектлары, шулай ук коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен, Министр тарафыннан җибәрелергә мөмкин.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза турында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары белән расланган Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә, әлеге Тәрти, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән методика

нигезендә вазыйфаи зат тарафыннан үткәрелә.

2.5. Вазыйфаи зат экспертизага тәкъдим ителгән актта һәм акт проектында коррупциоген факторларның булуын яки булмавын билгели.

2.6. Коррупциягә каршы экспертизаны гамәлгә ашыру барышында вазыйфаи зат, кирәк булган очракта, коррупциягә каршы экспертизада кызыксынучы структур бүлекчәләрдән һәм вазыйфаи затлардан өстәмә материаллар яисә мәгълүмат соратырга һәм алырга хокуклы.

Соратып алына торган материаллар һәм мәгълүмат вазыйфаи затка запросны алу мизгеленнән өч көннән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

2.7. Норматив хокукый акт проектына, шул исәптән бәйсез рәвештә, коррупциягә каршы экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү стадиясендә эшләүче тарафыннан юк ителә. Эшләүче тарафыннан норматив хокукый акт проектына кертелгән очракта, кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрелергә тиеш.

2.8. Актларга (актлар проектларына) коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты ун көннән дә артык түгел.

## III. Министрлык актына (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәсен әзерләү

3.1. Экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча вазыйфаи зат әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә форма буенча бәяләмә төзи.

3.2. Нәтиҗәдә түбәндәге мәгълүматлар чагылдырыла:

экспертизага тәкъдим ителгән актның (акт проектының) исеме һәм реквизитлары;

экспертиза үткәрү өчен нигез;

анализлана торган актта (акт проектында) коррупциоген факторлар булу яки булмау;

акт проектының коррупциоген факторлар булган конкрет нигезләмәләре;

хокукый нормаларның формулировкаларын үзгәртү буенча яисә коррупциогенлыкны бетерү өчен аерым нормаларны бетерү буенча тәкъдимнәр.

3.3. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча төзелгән, вазыйфаи зат тарафыннан әзерләнгән һәм имзаланган бәяләмә әлеге актны (акт проектын) коррупциягә каршы экспертизага җибәргән затка җибәрелә.

## IV. Коррупциягә каршы экспертиза бәяләмәсен үтәү

4.1. Коррупциягә каршы экспертизага җибәрелгән актта коррупциоген факторлар ачыкланса, аның инициативасы буенча акт кабул ителгән структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмәне алгач, өч көн эчендә үзгәрешләр кертү йә коррупциягә каршы экспертиза предметы булган актның үз көчен югалтуын тану турында норматив хокукый акт проектын әзерләргә һәм вазыйфаи затка коррупциягә каршы экспертиза уздыру өчен җибәрергә тиеш.

Тәкъдим ителгән үзгәрешләр кертү турында акт проектында коррупциоген факторлар булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат тарафыннан аның инициативасы буенча акт кабул ителгән структур бүлекчә җитәкчесенә җибәрелә, һәм структур бүлекчәләрнең кызыксынган җитәкчеләренең визалары белән акт проекты Министрга имзага җибәрелә.

Тәкъдим ителгән үзгәрешләр кертү турында акт проектында коррупциоген факторлар булган очракта, вазыйфаи зат бәяләмәне Министрга җибәрә. Министр бәяләмәне структур бүлекчә җитәкчесенә Бәяләмәдә булган нәтиҗәләргә туры китереп үтәү өчен җибәрә.

4.2. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупциоген факторлар юк икән, акт проектын эшләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләренең визалары белән акт проектын Министрга имзага җибәрә яки актны кызыксынган органнарга һәм оешмаларга килештерү өчен җибәрүне тәэмин итә.

4.3. Әгәр экспертизага җибәрелгән акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланган булса, акт проектын эшләү өчен җаваплы структур бүлекчә җитәкчесе, бәяләмәне алгач, өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне бетерергә һәм яңадан коррупциягә

каршы экспертизага вазыйфаи затка эшләп бетерелгән акт проектын җибәрергә тиеш.

Кабат коррупциягә каршы экспертиза үткәрү вакыты өч көннән дә артмый.

Эшләп бетерелгән акт проектында коррупциоген факторлар булмаган очракта, бәяләмә вазыйфаи зат тарафыннан имзалана, һәм акт проекты, кызыксынган структур бүлекчәләр җитәкчеләренең визалары белән, Министрга кул куярга җибәрелә.

Эшләп бетерелгән акт проектында коррупциоген факторлар булган очракта, вазыйфаи зат бәяләмәне Министрга җибәрә. Министр бәяләмәне структур бүлекчә җитәкчесенә Бәяләмәдә булган нәтиҗәләргә туры китереп үтәү өчен җибәрә.

Структур бүлекчә җитәкчесе өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне бетерергә һәм структур бүлекчәләрнең кызыксынган җитәкчеләренең визалары белән эшләп бетерелгән акт проектын Министрга имзага җибәрергә бурычлы.

4.4. Коррупциягә каршы экспертизаның барлык бәяләмәләре актка (акт проектына) тегелә һәм бергә саклана.

V. Актларга һәм акт проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү

5.1. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары булып «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында www.mert.tatarstan.ru(алга таба – сайт) рәсми рәвештә урнаштырылган Министрлык актлары һәм Министрлык актлары проектлары тора.

5.2. Министрлык актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын карау өчен юридик бүлеккә җибәргән эш көне дәвамында акт проектын сайтка урнаштыра, эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен адресны (шул исәптән электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау даталарын күрсәтә.

5.3. Сайтта урнаштырылган актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты кимендә биш эш көне тәшкил итә.

5.4. Министрлыкка кергән актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә (алга таба – бәяләмә) Министрлыкның актны (акт проектын) әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсенә карау өчен җибәрелә.

5.5. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә тәкъдим итү характерына ия һәм Министрлык тарафыннан аны алган көннән 15 көн эчендә мәҗбүри каралырга тиеш. Карау нәтиҗәләре буенча бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка, бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш, нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.6. Актка (акт проектына) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар акт проектын эшләп бетерү стадиясендә эшләүче тарафыннан юк ителә.

5.7. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсендә бәян ителгән кисәтүләрне юкка чыгарганнан һәм тәкъдимнәрне искә алганнан соң, Министрлыкның акт проектын әзерләү өчен җаваплы структур бүлекчәсе акт проектын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча кергән бәяләмәләрне кушып, кабат карап тикшерү өчен, юридик бүлеккә тапшыра. Кабат карау өч көн эчендә башкарыла.

5.8. Әгәр коррупциоген факторлар актта ачыкланган булса, Министрлыкның әлеге актны әзерләгән структур бүлекчәсе, Министрлыкта бәяләмә теркәлгән көннән алып өч көн эчендә актка үзгәрешләр кертү яки аны үз көчен югалткан дип тану чараларын күрә.

5.9. Министрлык актларында һәм Министрлык тарафыннан эшләнгән актларла коррупциоген факторлар булуын таныклый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта,... законда билгеләнгән тәртиптә Министрлык күрсәтелгән актларны (актлар проектларын) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгы нигезләмәсен кушып, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына коррупциягә каршы экспертизага җибәрә

5.10. Эшләүченең Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертелә торган федераль закон проектларында, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы Президенты указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуын турында таныклый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән килешмәве очрагында, эшләүче күрсәтелгән норматив хокукый актлар проектларын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына карауга кертә.

Норматив хокукый актларга һәм һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә 1 нче кушымта

**Коррупциягә каршы экспертизага кергән норматив хокукый актларны һәм норматив хокукый актлар проектларын исәпкә алу журналы**

| Актны (акт проектын) экспертизага кабул итү датасы | Актны (акт проектын) кабул иткән структур бүлекчәсенең атамасы | Актның (акт проектының) исеме | Вәкаләтләрне кабатлау | Коррупциоген факторларның булу/булмавы | Экспертиза үткәрү вакыты | Бәяләмә бирү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

Норматив хокукый актларга һәм һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү Тәртибенә 2 нче кушымта

БӘЯЛӘМӘ

дата ____ № _________

карар проектына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча

___________________________________________________

(норматив хокукый акт яки норматив хокукый акт проектының атамасы)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883 номерлы карары нигезендә коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде

_______________________________________________________________

(норматив хокукый акт яки норматив хокукый акт проектының атамасы) Коррупциоген факторлар ачыкланды (ачыкланмады).

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатларында тәкъдим ителә

_________________________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысулы күрсәтелә)

_________________________________________________________

(вазыйфа атамасы) (имзалар) (инициаллар, фамилия)